ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 Олы Кайбыч ав. № 517

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 31 мартындагы 162 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы «исем» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәт өчен түләү шартлары турындагы типлашкан нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 22 августындагы под-1344/25 номерлы карары нигезендә, мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү мәсьәләләре буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 31 мартындагы 162 номерлы карарына (2024 елның 02 апрелендәге 114 номерлы, 2024 елның 07 августындагы 286 номерлы, 2024 елның

25 декабрендәге 483 номерлы, 2025 елның 22 апрелендәге 108 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

2 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | база окладының айлык күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүтенче квалификация дәрәҗәсе | өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (башлыгы): муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган | - | - | 24690,0». |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек | | | |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров